**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 27 июнь № 444

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль берәмлекләр оешканчы, берләшкәнче, бүленгәнче яки аларның статусы үзгәргәнче төзелгән һәм Татарстан Республикасының муниципаль архивларында саклана торган архив документлары милкен аеру турында» 2007 ел, 28 май, 203 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына архив эше өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 ел, 24 декабрь, ТРЗ-63 нче Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру һәм Татарстан Республикасының муниципаль архивларында саклана торган, Татарстан Республикасының дәүләт милкенә караган архив документларын исәпкә алуны тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль берәмлекләр оешканчы, берләшкәнче, бүленгәнче яки аларның статусы үзгәргәнче төзелгән һәм Татарстан Республикасының муниципаль архивларында саклана торган архив документлары милкен аеру турында» 2007 ел, 28 май, 203 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 6 август, 624 нче; 2015 ел, 17 сентябрь, 685 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль берәмлекләр оешканчы, берләшкәнче, бүленгәнче яки аларның статусы үзгәргәнче төзелгән һәм Татарстан Республикасының муниципаль архивларында саклана торган архив документлары милкен аеру һәм Татарстан Республикасының муниципаль архивларында саклана торган, Татарстан Республикасының дәүләт милкенә караган архив документларын исәпкә алуны тәэмин итү турында»;

2 нче пунктта:

беренче абзацта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсенә» сүзләрен «Архив эше буенча Татарстан Республикасы дәүләт комитетына» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«ел саен, хисап елыннан соң килә торган елның 15 февраленә кадәр, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына архив эше өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 ел, 24 декабрь, ТРЗ-63 нче Татарстан Республикасы Законы нигезендә, хисап елыннан соң килә торган елның 1 гыйнвары хәленә карата Татарстан Республикасының дәүләт милкенә караган һәм аларны саклау, туплау, исәпкә алу һәм файдалану Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган архив документларын исәпкә алу документларына үзгәрешләр кертүне тәэмин итәргә;

6 нчы пунктта Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе» сүзләрен «Архив эше буенча Татарстан Республикасы дәүләт комитеты» сүзләренә алмаштырырга;

бу карарга 2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\444.docx

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 28 май, 203 нче карарына 2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 27 июнь, 444 нче карары редакциясендә)

2016 елның 1 гыйнвары хәленә карата
муниципаль берәмлекләр оешканчы төзелгән һәм муниципаль архивларда саклана торган, Татарстан Республикасының дәүләт милкенә кертелгән архив документлары, шулай ук муниципаль берәмлекләр территориясендә эшчәнлекләрен гамәлгә ашыручы һәм муниципаль архивларны туплау чыганагы булган (Татарстан Республикасы) дәүләт оешмаларының 2007 – 2015 елларда муниципаль архивларга саклауга кертелгән архив документлары

| Т/с | Муниципаль архив исеме | Эшләр саны |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Әгерҗе муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 6997 |
| 2 | Азнакай муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 6394 |
| 3 | Аксубай муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 7283 |
| 4 | Актаныш муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 4610 |
| 5 | Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 5069 |
| 6 | Әлки муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 3387 |
| 7 | Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 12917 |
| 8 | Апас муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 4217 |
| 9 | Арча муниципаль районы башкарма комитеты аппаратының оештыру-гомуми бүлегенә караган архив эшләрен исәпкә алу һәм алып бару бүлекчәсе | 7043 |
| 10 | Әтнә муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 2059 |
| 11 | Баулы муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 7188 |
| 12 | Балтач муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 4155 |
| 13 | Бөгелмә муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 13314 |
| 14 | Буа муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 9915 |
| 15 | Югары ослан муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 4820 |
| 16 | Биектау муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 5298 |
| 17 | Чүпрәле муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 3636 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 18 | Алабуга муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 13081 |
| 19 | Зәй муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 7587 |
| 20 | Зеленодольск муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 16426 |
| 21 | Кайбыч муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 1694 |
| 22 | Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 5267 |
| 23 | Кукмара муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 5485 |
| 24 | Лаеш муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 5584 |
| 25 | Лениногорск муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 9037 |
| 26 | Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 8801 |
| 27 | Менделеевск муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 3949 |
| 28 | Минзәлә муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 5685 |
| 29 | Мөслим муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 4199 |
| 30 | «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге архивы» муниципаль казна учреждениесе | 10318 |
| 31 | Яңа Чишмә муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 2208 |
| 32 | Нурлат муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 6070 |
| 33 | Питрәч муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 5586 |
| 34 | Балык Бистәсе муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 4228 |
| 35 | Саба муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 4230 |
| 36 | Сарман муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 5949 |
| 37 | Спас муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 6625 |
| 38 | Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 7389 |
| 39 | Тукай муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 5013 |
| 40 | Теләче муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 1750 |
| 41 | Чирмешән муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 5036 |
| 42 | Чистай муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 11328 |
| 43 | Ютазы муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 3355 |
| 44 | Чаллы шәһәре башкарма комитетының эш башкару идарәсе архив бүлеге | 19538 |
| 45 | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының муниципаль архивы идарәсе | 18796 |
| | Барлыгы | 312516 |